Факил САФИН

# Керпенең шәһәргә сәяхәте



УДК 821.512.145-3-93:34-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
С24

*Рәссамы Миләүшә Вазиева*

**Сафин, Ф. М.**

С24 Керпенең шәһәргә сәяхәте : балалар өчен әкиятләр, хикәяләр / Факил Сафин ; [рәссамы Миләүшә Вазиева]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. — 151 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-03194-3

Кырмыска малае Кырмыч белән Чикерткә малае Чикертмән арасында дуслык буламы? Ак тузганакка кәрзин тагып, күккә күтәрелү мөмкин эшме? Трольләр кешеләрдән урлап җыйган хәзинәләрен кире кайтара аламы? Ф. Сафинның әлеге китабында шушы һәм башка сорауларга җавап табарга мөмкин.

УДК 821.512.145-3-93:34-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-03194-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Сафин Ф. М., 2016



# ЧИКЕРТКӘ МАЛАЕ ЧИКЕРТМӘН БЕЛӘН КЫРМЫСКА МАЛАЕ КЫРМЫЧ ТУРЫНДА ӘКИЯТ

*(Әкият-повесть)*

Борын-борын заманда, сулга китеп йөз чакрым, уңга китеп бер чакрым, килеп җиткәч Иделгә, бәлки, Чулман буена, бәлки, Агыйдел ярына; теплоходта йөзгәчтен, самолётта очкачтын, машинада җилдергәч, көлмәсләрне көлдергәч; камышлар — яшел толым, уйнап йөргәндә колын, килеп җитәсең бер илгә, исеме аның — Болын.

Менә шушы Болында яши дөньяда иң җитез һәм тиктормас бер малай. Исеме үзенә бик килешле — Чикертмән. Әнисе Сикертмәния апа үзенең бик тә бик тә яраткан малаен акыллы һәм зирәк итеп үстерергә тели. Аңа төрле китаплар сатып алып кайта. Малайның акылы ай үсәсен көн үсә. Баштарак Чикертмән уйнау-

дан бушамаса, тора-бара китаплар укырга, рәсем ясарга остарып киткән. Чикерманнең заманнан бер дә калышасы килми, аның скутеры да, планшеты да, кәрәзле телефоны да бар. Өйләрендә нинди генә уенчыклар юк!

Болын – бик матур ил ул. Бу гүзәллекне сөйләп бетермәле түгел. Андагы үләннәрнең, чәчәкләрнең, бөҗәкләрнең исәбе-хисабы юк. Чикертмән дуслашырга ярата. Бигрәк тә кырмыска малае Кырмыч белән дус ул.

Болында тагын Әкәм Төкәмеч, чуар камка малае Коңгырт, кигәвен малае Кигәк, Олы күлдә яшәүче яшел бака, Су чикерткәсе, тагын әллә кемнәр бар. Тагын җилләр бар. Ни өчен җилләр дим, чөнки Шаян җил, Назлы җил, Усал җил дигәннәре бар аларның.

Бу ике малай алар белән дә еш очрашып торалар. Чикертмән белән Кырмычның Болын илендә ни-нәрсәләр күргәннәрен сезгә дә сөйләп бирим әле.

## КОТКАРЫГЫЗ, ЯРДӘМ КИРӘК!

Җәйнең иң матур көне булгандыр бу. Зәп-зәңгәр тирән күктә кояш көлеп тора. Ул җирдәге һәммәсен күрә, төрле җан ияләренең ямьле көнгә шатланып йөрүләренә куанып бетә алмый. Белә бит ул, әгәр кара болыт чыгып, күк йөзен бөтенләй каплап алса, аның мәрхәмәтле нурлары җиргә барып җитә алмыйлар, ул чакта һәммә җан ияләре – кешеләр, хайваннар, төрле-төрле бөҗәкләр, агачлар, үләннәр, берсеннән-берсе матур гөлләр – рәхәтләнеп үсә алмаслар иде. Аларның кәефләре китәр иде. Мондый вакытларда шыксыз җил исә башлый, чәчәкләр йомылалар, барлык җан ияләре салкын җилдән ышык эзлиләр. Үткән көнне шулай булган иде.

Ә бүген күңелле! Кояш торган саен югарыга күтәрелә. Рәхимле нурлары белән һәммәсен-һәммәсен иркәли. «Үсегез, якты көннең кадерен белегез!» – ди ул.

Назлы җил исеп китте, назлап, чәчкәләрнең таҗларын сөеп алды. Шуны гына көткән кебек, бөтен болын хәрәкәткә килде:



иреккә чыккан шикелле, офыкка табан болын буйлап чәчкәләр йөгерешә башлады, аларга үләннәр кушылды. Җир өстендә җыр яңгырады:

И болын, иркен илем,
Яшел бишегем минем! –
Битләремнән сыйпап үтә
Ягымлы, назлы җилең.

Бу җырны кыяк үлән өстенә менеп, таган атына-атына җырлаучы – Чикерткә малае Чикертмән иде.

Кичә ул бик уйный алмады. Иртән уяныл, йоклаган яфрак астыннан чыгып, кыяк үлән өстендәге таганына менеп ятуга, әллә каян салкын җил килеп чыгып, аның башындагы эшләпәсенә бәйләнә башлады. Чикертмән эшләпәсен бик ярата, бу күз явын алырлык эшләпәне әнисе аңа үзе тегеп биргән иде. Җил эшләпәне тарткалый, йолкып алып, әллә кая илтеп ташламакчы була. Чикертмән ике кулы белән чытырдап эшләпәгә тотынды. Ул арада ерактан-ерактан кара болыт килеп чыкты, тотынды яңгыр коярга, тотынды яңгыр коярга. Кыяк үлән астыннан, котырып, елга ага башлады. Чикертмән шушы ташыган елгага барып төшә язды. Ярый әле аяклары көч җыйнап өлгергәннәр иде, алар егылырга ирек бирмәделәр. Чикертмән көч-хәл белән кире әрекмән яфрагы астына кереп егылды. Көне буе башын да чыгарып карамады, бик курыккан да иде, җил белән тарткалашып, хәле дә бетеп китте, көне буе, төне буе йоклады.

Ә бүген шә-әп! Кояш нурлары шундый иркәли, таган атынган көйгә һаман-һаман кычкырыбрак җырлый Чикертмән:

Кояш мине ярата,
Мин кояшны яратам.
Мин үссен дип, кояшкай
Җылы нурын тарата!

Болыным – хәтфә үлән,
Гөлдән гөлгә сикерәм.
Мин бик җитез, бик зирәк,
Миндәй малайлар сирәк!

Җырын тәмамларга өлгермәде, колагына нindидер сыкранган тавыш ишетелеп китте.

Чикертмән, тын калып, тирә-юньне күзәтә башлады. Кемдер ярдәм сорап кычкыра иде:

– Коткарыгыз, ярдәм итегез!

Шундый нурлы көннең ямен җибәреп, кем кычкыра анда? Кемне, нәрсәдән коткарырга?

Чикертмән кыяк үлән төбенә карады.

Анда, мыегын кызганыч селкеткәләп, кырмыска малае Кырмыч тавышлана икән.

– Нәрсә булды сиңа? Минем җырымны бозып, ник тавышланасың? – диде Чикертмән, үртәлеп.

Кырмыч, Чикертмәннең тавышын ишеткәч, сөенеченнән мыегы белән кыяк үләннең сабагын сыйпап алды.

– Коткар, Чикертмән, аягыма таш тәгәрәп төште. Һич ала алмыйм. Булыш әле...



Чикертмән кичә үзенең җил белән тарткалашуын, яңгырдан качып җәфаланганын исенә төшерде. Һи, коткар, булыш, имеш. Аңа менә беркем дә булышмады. Үзе ничек итсә итте, исән-имин әрекмән яфрагы астына кайтып ятты. Эшләпәсен дә җилгә бирмәде. Менә шулай кыю, көчле булырга кирәк.

– Нәрсә кычкырасың? – диде Чикертмән, таганыннан башын күтәреп. – Ник ул таш астына аягыңны китереп кыстырдың? Кем кушты? Хәзер мин шул ташны синең аягың өстеннән алам дип җәфаланыймммы? Ничек кыстырган-

сың аягыңны, шулай ал! Бетмәс синең ише Кырмыч-мырмычлар. Миңа кирәк чагында, берегез дә күренмисез.

Кырмыч Чикертмәннең сүзләрен көчкә генә түзеп тыңлап торды. Аягы бик авырта шул. Таш авыр, һич кенә кузгатмалы түгел.

– Үзең дә күргәнсеңдер, бер малай, кармаклар күтәреп, инеш буена китеп бара иде, менә шушы сукмактан... – диде Кырмыч.

– Йә, шуннан? – диде Чикертмән, тәмам кәефсезләнеп. – Мин аны көн дә күрәм. Көн саен инеш буена кармак күтәреп китә ул. Көне буе утырып, бер балык та капмый үзенә. Пешмәгән малай булып чыкты.

– Менә шул малай турында әйтәм инде. Бүген дә сызгырасызгыра инеш буена китте, сукмак өстендә яткан бер ташны тибеп җибәргән иде, нәкъ минем аяк өстенә килеп төште. – Кырмыч түземен җуеп сызланып алды. – Ай-яй, бигрәк авырта аягым, ничек тә ала алмыйм бит. Ярдәм ит әле, Чикертмән. Үзем дә сиңа булышыр идем...

Чикертмән көлеп куйды:

– Һа, булышчы табылды! Син миңа булышканчы, Усал җил минем эшләпәмне мең мәртәбә йолкып ала. Мин үземә генә ышанам! Көтмә дә, сиңа ярдәм итәргә вакытым юк. Бер аякны таш astыннан сөйрәп чыгармаска соң, бигрәк җебегән икәнсең!

– Сөйрәп чыгарырга тырышып карадым, авырта бит, аягым имгәнеп харап булмасын дим, – диде Кырмыч, Чикертмәннең кыланмышын килештермичә.

Чикертмән аны тыңлап тормады.

– Әнә әнием чакыра, берәр ризык тапкандыр. Сыйлыйсы киләдер мине, – дип, кыяк үләннән каядыр сикереп юк булды.

Кырмычның бәхетенә, шушы тирәдә генә абыйлары нидер эшләп йөриләр икән, алар, энеләренең тавышын ишетеп, тиз арада килеп җиттеләр, ташны бер читкә этәреп, Кырмычны бәладән коткардылар.

Бу хәлне Кырмыч онытып бетергән иде. Көн кичкә авышып барганда, колагына сәер сызгырулы тавыш ишетелде:

– Коткарыгыз, аһ, коткарыгыз! Эләктем, эләктем...



Кырмыч тавыш килгән якка йөгерде. Аягы авыртканын да уйлап тормады хәтта.

Олы әрекмән сабагында чайкалып торган Чикертмәнне күреп шаклар катты кырмыска малае.

– Нәрсә булды? Үзең таган атынасың, үзең ярдәм сорап кычкырасың, – дип сөйләнеп алды Кырмыч.

– Нинди таган булсын! – дип ачыргаланып елый ук башлады Чикертмән. – Инде ярты көн интегәм. Кычкырам, беркем дә килеп карамый. Күрмисеңмени, пәрәвезгә эләкте бер аягым, ычкынмакчы булып тырыша торгач, аягым тартылып озынаеп бетте инде. Тагын бераз торсам, өзелеп төшәр әле. Үрмәкүч килеп чыкса, бөтенләй эш харап, кабып кына йотачак! – Чикертмән елаудан шешенгән күзен Кырмычка төбәде. – Коткар, зинһар өчен, коткар мине! – дип ялынды ул.

Мондый вакытта, сүз сөйләп, вакытны әрәм итәсе түгел.

Кырмыч үткен теше белән пәрәвез җебен кисәргә тотынды.

– Ай-яй каты-ы, – диде ул, бераз маташкач. – Тимердән дә каты бу.

– Һе, шулай булмаса, мин аны бер селтәнүдә өзгәләп бетерер идем, – диде Чикертмән.

Кырмыч, аның сүзләренә игътибар итмәстән, тагын да тырышыбрак, җеп кисүне дәвам итте. Ниһаять, җеп шартлап өзелде, Чикертмән шап итеп бака яфрагы үләне өстенә барып төште. Бераз аңгыраеп яткач, озын мыегын селкеткәләп, тәнен капшап чыкты.

– Исән икән... – диде ул, Кырмыч ягына үпкәле караш ташлап. – Әллә җеп белән минем аякны да өзеп төшердең микән дип торам.

Кырмыч, Чикертмәнне коткара алуына күңеле булып, кире китеп бара иде инде.

Чикертмән, тәмам һушына килеп, аның артыннан кычкырып калды:

– Гафу ит, Кырмыч. Теге чакта, сиңа ярдәм итмичә, зур хата ясадым. Моннан соң алай итмәм... Бер-беребезгә булышып яшик!

Кырмыч, бу сүзләргә сөенеп, ике кулын чәбәкәйләп алды.

## ЕРАК БОЛЫНГА СӘЯХӘТ

Чикертмән үлән төпләреннән боргаланып-сыргаланып үткән сукмактан Кырмыч узмасмы дип озак күзәтте. Ниһаять, борылыштан бернигә исе китмәгән кыяфәттә ашыкмыйча үзләренә таба килүче Кырмычны күреп алды. Үтеп китмәсен дигәндәй, Чикертмән ачы итеп сызгырып җибәрде.

Кырмыч, барган җиреннән туктап, кыска мыегын мәзәк кенә уйнатып алды.

— Кем ул анда җил чакырып сызгырып маташа, — диде ул төксе рәвештәрәк.

— Мин сызгырган саен, җил чыга башласа… — диде Чикертмән.

— Синең шул инде, чер-р дә чер-р. Сызгыра торгач, иренең ярылып беткән.

— Ә синең башыңда эшләпәң юк.

— Минем кәпәчем үземә бик килешеп тора, — дип, Кырмыч кәпәчен алып югарыга чөйде. Кәпәч сырганак үләне кырмавычына килеп эләкте. Кырмыч кәпәчен тиз генә алмакчы иде, кырмавыч кәпәчкә шытырдап ябышырга да өлгергән.

— Әйтәм бит, синең сызгыруың җүнлелеккә түгел, — диде, авызын турсайтып. — Әйдә, булыш, бу кырмавыч кадәр башкаларга зыян салырга гына торган башка үсемлек юктыр. Чат ябышты минем кәпәчемә.

Чикертмән, тиз генә төшеп, кәпәчне кырмавычтан йолкып алырга маташа башлады. Аның да көче җитмәде.

— Карап торма, миңа булыш, — диде Чикертмән Кырмычка.

Икәүләп азаплана торгач, кәпәчне кырмавыч кулыннан йолкып алдылар. Кырмыч кәпәчен, каккалап, башына киеп куйды.

— Синең аркада… — Кырмыч сүзен әйтеп бетермәде.

— Йә, шулай юкка-барга күңелсезләнеп утырабызмы инде? — диде Чикертмән, Кырмычның күңелен күтәрергә тырышып.

— Нишлик соң? — диде Кырмыч аптыраган кыяфәт белән. —

Барам дисәң, барыр җир юк. Кунакка чакыручылар күп, барсаң, берсе дә өйдә түгел.

Чикертмәннең башына кинәт уй килеп төште:

– Әйдә, Кырмыч, сәяхәткә чыгабыз!

– Сәяхәткә?.. – Кырмыч аптырап калды. – Мин бит озаклап йөри алмыйм. Төшке аш вакытында гына уйнарга чыгып кермәкче идем.

– Ә без озак йөрмәбез.

– Кая барабыз соң? Сәяхәт булгач, без каядыр чыгып китәргә, илләр, җирләр гизеп кайтырга тиеш булабыз ич.

– Әйе шул, илләр-җирләр гизеп кайтыйк. Безгә кем комачаулый?

– Әйдә дә әйдә. Кая барабыз? Синнән шуны сорыйм мин. Якындагы ат кузгалагы тирәсеннән урап кайтсак кына инде.

– Мең тапкыр күргән инде аны. Җитмәсә, аннан ниндидер ис килә.

– Кузгалак кислотасы, диләр аны. Кемгәдер файдасы да тия икән, дару үләне, диләр.

– Аның исеннән башым әйләнә. Минем ераккарак китәсем, сулар кичәсем, яңа җирләр күрәсем килә.

– Андый җир бармы соң?

– Нишләп булмасын, – диде Чикертмән котелмәгәнчә көр күңел белән. – Әнә тал төбендә Олы күл бар. Шуны йөзеп чыгыйк та без моңарчы булмаган Аръяк болынлыкта уйнап йөрик. Анда җиләкләр дә күп икән, мин мәмрәп пешкән җиләкне бик яратам.

– Таллыктагы Олы күлне йөзеп чыгарга? Башың икедер синең. Олы күл бит ул! Җиләк дигәндә... Мин дә яратам шул аны.

– Олы күл дигәннән, яңгыр явып үткәч барлыкка килде инде ул. Көннәр болай эссе торса, күлнең эзе дә калмаячак. Соңга калганчы, шунда йөзеп алыйк.

– Мин йөзә беләм дә, тик Олы күлгә керергә куркам.

– Мин дә аны сикереп кенә чыгар идем дә, киңрәк шул. Бер

сикерүдә чыгып җитә алмам. Әни гел әйтеп тора, таллыктагы Олы күлдә яшел бака яши икән, мин күзенә чалынсам, әһ тә итми кабып йотачак, ди.

– Нинди генә җан иясе юк бу дөньяда, – дип, Кырмыч, күзен кыса төшеп, Чикертмәнгә баштан алып аягына кадәр күз ташлап алды. – Синең кай төшеңне ашарлык инде?

– Ашый дигәч ашый инде. Бик куркыныч ул яшел бака. Син көне буе йөгереп үткәнне бер генә ыргып ала ул. Күргәнем бар.

– Алайса, йөрмик анда.

– Ә без сиздерми генә барабыз да, берәр көймә табып, күлне кичеп чыгабыз. Аннан болында рәхәтләнеп җиләк белән сыйланабыз.

Чикертмән белән Кырмыч сөйләшә-сөйләшә таллыктагы Олы күл янына төшеп киттеләр. Артык ерак түгел иде күл, тиз килеп җиттеләр.

Яр буенда көймә күренмәде.



# ЭЧТӘЛЕК

Чикерткә малае Чикертмән белән кырмыска малае Кырмыч турында әкият *(Әкият-повесть)* . . . . . . . . . . 3
Яңа ел маҗарасы *(Әкият-повесть)* . . . . . . . . . . 78
Керпенең шәһәргә сәяхәте . . . . . . . . . . 111
Кояшсылу турында әкият . . . . . . . . . . 121
Кышның беренче көне . . . . . . . . . . 124
Язгы тамчылар . . . . . . . . . . 129
Ләлә белән Арслан . . . . . . . . . . 131
Болан Кояшны ничек коткарган? . . . . . . . . . . 137
Үлән урманы . . . . . . . . . . 141
Кызыктырган иде... . . . . . . . . . . 144
Фазыл чишмәсе . . . . . . . . . . 146
Сыерчык . . . . . . . . . . 149